# Аннотацияләр

**5 нче сыйныф (рус төркеме) өчен туган телдән эш программасына аннотация.**

**Эш программасында бирелгән сәгатьләр саны**: елга  70 сәгать, атнага 2 шәр сәгать.

**УМК:** Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар

телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы, 1 — 11 нче сыйныфлар, (төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева ) Казан 2014;

Дәреслек: Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) Авторлары: Р.З.Хәйдәрова,Г.М Әхмәтҗанова “Татар теле” 5 сыйныф, Казан ”Татармультфильм” нәшрияты, 2014.

**Эш программасының максаты:** Укучыларның башлангыч сыйныфта үзләштерелгән белемнәрен камилләштерү һәм тирәнәйтү; алган белемнәрне аралашуда кулланырга өйрәтү.

**Программаның эчтәлеге** түбәндәге темаларны үз эченә ала: “Без мәктәптә”“Мин-өйдә булышчы” , “Дуслар белән күңелле” ,”Дүрт аяклы дусларыбыз”,” Без спорт яратабыз”.

**Тикшерү төрләре:** бүлекләр буенча мөстәкыйль, контроль эшләр, әңгәмә, диалогик һәм монологик сөйләм.

**7нче сыйныф (рус төркеме) өчен туган телдән эш программасына аннотация.**

Эш программасында бирелгән сәгатьләр саны: елга 70 сәгать. атнага 2 шәр сәгать

**УМК:** Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы, 1 — 11 нче сыйныфлар, (төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова,Р.Л. Малафеева) Казан 2014; Дәреслек: Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) Авторлары:

Р.З.Хәйдәрова, Р.Л, Малафеева. “Татар теле” 7 сыйныф, Казан ”Татармультфильм” нәшрияты, 2014.

**Гомуми белем бирү максаты:** Укучыларның үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү һәм тирәнәйтү. Мөстәкыйль һәм бәйләгеч сүз төркемнәрен телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.

**Программаның эчтәлеге** түбәндәге темаларны үз эченә ала: “Белем һәм тормыш”, “Без бергә ял итәбез”, “Өлкәннәр һәм кечкенәләр”, “Без Татарстанда яшибез.”

**Тикшерү төрләре:** бүлекләр буенча мөстәкыйль, контроль эшләр, әңгәмә, диалогик һәм монологик сөйләм.

**8нче сыйныф өчен туган телдән эш программасына аннотация.**

**Эш программасында күрсәтелгән сәгатьләр саны:** елга -70 сәгать , атнага 2 шәр сәгать

**УМК:** Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен үрнәк программа. Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы,1 -11 нче сыйныфлар ( төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева). – Казан: “Татарстан китап нәшрияты”, 2011.

Дәреслек:Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең. 8 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен/ Татар теле. Р.З. Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева Казан ”Татармультфильм” нәшрияты, 2015

**Гомуми белем бирү максаты:**

Укучыларның гомуми белем мәктәбендә үзләштерелгән белемнәрен камилләштерү һәм тирәнәйтү; тел күренешләрен танып белергә, чагыштырырга, гомумиләштерергә күнектерү; татар телен халыкның рухи, әхлакый, мәдәни хәзинәсе буларак аңларга ирешү.

**Программаның эчтәлеге** түбәндәге темаларны үз эченә ала: “Күп укыган-күп белер” , “Мин һәм минем яшьтәшләрем”, “Буш вакытымны мин ничек үткәрәм?”, “Табигать һәм кеше” , “Без Татарстанда яшибез” ,“Татарстанның күренекле әдипләре” .

**Тикшерү төрләре:** контроль һәм мөстәкыйль эшләр.

**9нчы сыйныф өчен туган телдән эш программасына аннотация.**

**Эш программасында күрсәтелгән сәгатьләр саны:** елга -68 сәгать , атнага 2 шәр сәгать

**УМК:** Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен үрнәк программа. Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы,1 -11 нче сыйныфлар ( төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева). – Казан: “Татарстан китап нәшрияты”, 2011.

Дәреслек:Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең. 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен/ Татар теле. Р.З. Хәйдәрова,Р, Ибрагимова Г.И.,.Л.Малафеева Казан ”Татармультфильм” нәшрияты, 2016

**Гомуми белем бирү максаты:**

Укучыларның гомуми белем мәктәбендә үзләштерелгән белемнәрен камилләштерү һәм тирәнәйтү; тел күренешләрен танып белергә, чагыштырырга, гомумиләштерергә күнектерү; татар телен халыкның рухи, әхлакый, мәдәни хәзинәсе буларак аңларга ирешү.

**Программаның эчтәлеге** түбәндәге темаларны үз эченә ала: “Без Татарстанда яшибез”.“Китап-киңәшчем,дустым минем”.“Һөнәр сайлау”.“Аралашу әдәбе”.“Буш вакыт”.“Табигать һәм кеше”.“Беркем дә,бернәрсә дә онытылмый”.

**Тикшерү төрләре:** контроль һәм мөстәкыйль эшләр.

МБОУ «Кубасская основная общеобразовательная школа»
Чистопольского муниципального района РТ

Согласовано»
Руководитель МО
_______Шавалиева С.Б
протокол № 1от26.08.2020 г

«Согласовано»
Заместитель директора по УР
МБОУ «Кубасская ООШ»
_______ Бусыгина А.С.
.08. 2020.

«Утверждаю»
Директор МБОУ
«Кубасская ООШ»
_______ Павлиева Л.А.
Приказ № от .08. 2020 г.

# Рабочая программа
## по родному языку(тат) для 5-9 классов (ФГОС)
## Сафиуллиной Г.Р. учителя первой квалификационной категории

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол №1 от26 .08.2020г.

2020-2021 учебный год

АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**5-9 нчы сыйныфлар өчен туган телдән эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:**

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации) №273-ФЗ от 29.12.2012

2. Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан республикасы Законы.22.06.2013 №68/ЗРТ

3. ТР Чистай муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Кубас төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2020-2021 уку елына “Төп белем бирү программасы”.

4.Программа: Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы, 1 – 11 нче сыйныфлар, Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011 ел.

5. ТР Чистай муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе “Кубас төп гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2020-2021 уку елына базислы уку планы

6.. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы.

- 6 статья – белеем алу теле (телләре)

- 7 статья – мәгарифнең дәүләт стандартлары

-10 статья –уку-укыту программалары

- 32 статья – мәгариф учреждениесенең вәкаләтләре һәм җаваплылыгы.

**Рус балаларына татар телен укытуның төп максаты**

Урта баскычта рус телле балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

**Танып белү максатының эчтәлеге**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Урта баскычта татар халкының рухи дөньясын чагылдырган, тормыш – көнкүрештәге әхләкый проблемаларны үз эченә алган, укучыларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры килгән әдәби әсәрләр белән танышу; Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

**Үстерү максатының эчтәлеге**

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне устерү.

Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда, бу максатлар беренче планга куела.

**Тәрбияви максатның эчтәлеге**

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Эчтәлектә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый. Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырыла, сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләртәкъдим ителә.

**Белем бирү максатының эчтәлеге**

Укучыларның  татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Бурычлары:**

- Укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру.

- Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү.

- Дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру.

- Төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү.

- Татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү.

- Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычны да үтәү мөһим.

- Аңа ирешү өчен, татар сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, әңгәмә корырга, фикер йөртергә, хәбәр итәргә күнектерү.

- Татар дөньясына караган милли традицияләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру һәм татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте турында мәгълүмат җиткерү .

**Программага эчтәлек сайлау үзенчәлекләре**

Программага сайланган эчтәлек гомуми белем бирү системасының фундаменталь нигезен тәэмин итә һәм урта гомуми белем бирү баскычында ул тирәнәйтелә. Шулай ук сайланган эчтәлек укучыны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү  максатына хезмәт итә; башлангыч гомуми белем бирү баскычы программасы белән дәвамчанлыкны саклый.

5 – 9 нче сыйныфларда телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятләргә карата ихтирам хисе уята, укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга һәм объектив бәяләргә мөмкинлек бирә.

Татар телен укыту 9 нчы сыйныфта концентрик юнәлештә оештырыла, ягъни 5–8 нче сыйныфлардагы укыту предметының эчтәлеге тирәнәйтелеп кабатлана.

Тел материалын өйрәнү 5–9 нчы сыйныфларда тәгәлләнә, ә югары баскычта барлык үзләштерелгән материал сөйләм эшчәнлеге барышында кабатлана һәм ныгытыла.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны**

**Мәктәпнең Уку планы буенча 2020-2021 нче уку елында татар теле укытуга урта баскычта**

**сәгатьләр саны түбәндәгечә бүленде:**

5 нче сыйныф – атнага 2 сәгать, елга 70 сәгать

7 нче сыйныф - атнага 2 сәгать, елга 70 сәгать

8 нче сыйныф – атнага 2 сәгать, елга 70 сәгать

Барлыгы - 210 сәгать

**Күнекмәләргә таләпләр:**

Гомуми белем мәктәбендә татар теле дәресләре укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелә, бу исә аларның тыңлап аңлау, сөйләү һәм сөйләшү, уку, язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен формалаштыруны үз эченә ала.

- тыңлап аңлау – аерым авазларны, иҗек калыпларын, сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләрне, бәйләнешле текстларны ишетеп, мәгънәләрен һәм эчтәлекләрен аңларга өйрәтү;

- диалогик сөйләмгә өйрәткәндә, укучыларның көндәлек тормышын чагылдыра торган табигый темаларга сөйләшүләрен формалаштыру;

- монологик сөйләмгә өйрәткәндә аерым кешеләрне, әйберләрне табигать күренешләрен, хайваннарны тасвирлауга, сыйныф, мәктәп, авыл, шәһәр тормышы

һ. б. турында хәбәр итүгә, укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген план буенча сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру;

- укуга өйрәткәндә, татар хәрефләрен танып, алар белдергән авазларны дөрес әйтү, дәреслектәге текстларны сәнгатьле итеп, йөгерек һәм аңлап уку күнекмәләре булдыру;

- яңа сүзләрне сүзлектән табу;

- язуга өйрәткәндә, сүзләрне иҗекләргә бүлеп, юлдан юлга дөрес күчерү кагыйдәләрен үзләштерү, сөйләмдә актив кулланыла торган сүзләрне орфографик дөрес язу күнекмәләрен үстерү;

- язма сөйләмгә өйрәткәндә, терәк сүзләр, сүзтезмәләр һәм үрнәк җөмләләргә нигезләнеп, өйрәнелә торган лексик тема яки бирелгән ситуация буенча җөмләләр яза белү.

Укучыларда фонетик күнекмәләр булдыру өчен, түбәндәгеләргә игътибар итү мөһим: татар теленә генә хас булган авазларның әйтелешен үзләштерү; татар һәм рус телләрендә уртак булган, ләкин әйтелешләре белән аерылган авазларны чагыштырып өйрәнү; авазларны сүзләрдә, сүзтезмәләрдә, җөмләләрдә, бәйләнешле сөйләмдә дөрес әйтүгә ирешү. Бу төр күнекмәләр булдыру өстендә эзлекле эшләү генә укучыларның сөйләмендәге фонетик хаталарны бетерергә мөмкинлек бирә.

Укучыларның **лексик күнекмәләрен** үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланышын үзләштерү шарт. Моның белән беррәттән, татар һәм рус сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару да, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала.

Укучыларның **грамматик күнекмәләрен** үстерү – төрле сүз төркемнәренең морфологик формалары, ясалышлары белән таныштыру, сүзләрнең җөмләдә үзара бәйләнеш чараларын үзләштерү һәм кагыйдәләрен белү дигән сүз. Татар телен икенче тел буларак укытканда, лексик-грамматик материалны синтаксик нигездә үзләштерү принцибына таянып эш итү кирәк, чөнки сүзләр башка сүзләр белән бәйләнештә булганда гына, җөмлә, гомумән, сөйләм барлыкка килә.

## Укытуның көтелгән нәтиҗәләре

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар  өчен булган катламы белән  танышу башка мәдәниятькә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Төп гомуми белем бирү баскычында татар теленә өйрәтүнең  программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

укучыларныңкоммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

“Татар теле һәм әдәбияты” предметынакарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Укытуның шәхси нәтиҗәләре**

Төп гомуми белем бирү баскычын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

“гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

**Укытуның метапредмет нәтиҗәләре**

Төп белем бирү баскычындататар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (*танып белү, регулятив, коммуникатив)*формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

***Танып белү универсаль уку гамәлләрее:***

фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;

объектларны  чагыштыру, классификацияләү  өчен уртак билгеләрне  билгеләү;

төп мәгълүматны  аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив универсаль уку гамәлләрее*:**

уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба  белү;

уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;

билгеләгән  критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;

укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;

ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм  алар белән дөрес эш итә белү;

дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникативуниверсаль уку гамәлләрее:***

әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;

әңгәмәдәш  белән  аралашу калыбын төзү;

аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

парларда һәм күмәк эшли белү;

мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш  башкару;

әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Предмет нәтиҗәләре**:

- укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;

- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

- “Татар теле һәм әдәбияты” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ТЕМАЛАРГА ЯКЫНЧА БҮЛЕНЕШЕ

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек** | **Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика** |
|---|---|
| **Сөйләмнең предмет эчтәлеге** | |
| **Мәктәп тормышы.**<br><br>Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу. Дәресләр расписаниесен, дәресләр әзерләү, әзерләмәүнең сәбәбен әйтә белү. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә тоту.<br><br>Китаплар дөньясы, китапханәгә бару, китап алу. Яхшы уку серләре , яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. Интернет аша үз белемеңне күтәрү. Белем алу һәм тормышта үз урыныңны табу проблемасы.<br><br>**Мин – өйдә булышчы.**<br><br>Өйдәге эшләр. Эш куша белү. Эш эшләргә риза булу (булмау). Өй эшләре буенча киңәш бирү. Яхшы эшләр өчен рәхмәт белдерү һәм мактау. Кибеткә бару, ашамлыклар, җиләк-җимеш, кием-салым сатып алу.Өйдәге хезмәттә катнашу, кешеләргә бәя бирү.<br><br>**Минем дусларым.**<br><br>Иң якын дустым. Дуслашу серләре. Дустымның сыйфатлары. Дустымның мавыгулары. | Күрсәтелгән темалар кысасында укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика “Сөйләм эшчәнлеге төрләре” бүлегендә бирелә. |

| | |
|---|---|
| Характер сыйфатлары.  Дуслар белән бергә ял итү. Дуслык кадере. Чын һәм ялган дуслык.<br><br>**Мин һәм минем яшьтәшләрем.**<br><br>Яшьтәшләрнең тышкы кыяфәте һәм эчке сыйфатлары. Матур киенү серләре.Яшьтәшләр белән аралашу кагыйдәләре.Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтендә алдашу, ялганлашу.Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы, гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алуы.<br><br>**Ял итү.** Буш вакыт: файдалы,  файдасыз үткәрү.  Яраткан шөгыльләр: музыка, бию, рәсем ясау, уку һ.б. Компьютерга бәйлелек. Виртуаль аралашуның төрле ысуллары. Ял көннәре. Ял итү урыннары (кино, театр,кафэ һ.б.) Караган фильм, андагы геройлар. Музыка һәм сынлы сәнгать, театр һәм кино белән кызыксыну.  Сәяхәт итү.<br><br>**Бәйрәмнәр.**<br><br>Бәйрәм белән котлау. Кунаклар чакыру. Бәйрәм табынын әзерләү. Кунакларны сыйлау. Яраткан (яратмаган) ризыклар. Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Туган көн.Туган көн уеннары. Милли бәйрәмнәр. Милли ризыклар.  Ашамлыклар һәм эчемлекләр. Төрле рецептлар.<br><br>**Дүрт аяклы дусларыбыз.**<br><br>Дүрт аяклы дусларның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре. Дүрт аяклы дусларга карата мәрхәмәтлелек. Бөек Ватан сугышында этләрнең батырлыклары.<br><br>**Без спорт  яратабыз.**<br><br>Сәламәт булу кагыйдәләре.<br><br>Җәйге, кышкы спорт төрләре. Яраткан спорт төре. Мәктәптә спорт ярышлары. Төрле спорт түгәрәкләре. Спорт белән шөгыльләнү. Спорт һәм ял. Спорт уеннары.  Татарстан спорт командалары. Заманча спорт корылмалары. Атаклы татар спортчылары. Халыкара спорт.<br><br>**Светофор – минем дустым.**<br><br>Юл йөрү кагыйдәләре. “Яшь юл хәрәкәте инспекторы (ЮИД)” эшчәнлеге, “Имин тәгәрмәч” | |

| | |
|---|---|
| республика конкурсы.<br><br>**Табигать һәм без.**<br><br>Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр, ел фасыллары. “Яшел планета” конкурсында, “Мин чисталык яратам”, “Кошларга ярдәм” акцияләрендә катнашу. “Кеше һәм табигать” проблемалары.<br><br>**Туган җирем –Татарстан.**<br><br>Татарстанның территориясе, аның географик урыны, климаты, файдалы казылмалары. Татарстанның табигате: елгалар, үсемлекләр, җәнлекләр; аларның атамалары, исемнәре. Татарстанда яшәүче милләтләр, төрле телләрдә сөйләшү. Халыклар дуслыгы. Татарстанның башкаласы Казан, аның бүгенге йөзе, тарихиистәлекләре, музейлары, театрлары,ял итү урыннары. Татар сәнгатенең күренекле вәкилләре.<br><br>**Өлкәннәр һәм без.**<br><br>Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәтләре. Өлкәннәрдән рөхсәт сорау.<br><br>“Ата-анага хөрмәт – мәңгелек” проблемасы.<br><br>**Әдәбият – сәнгать дөньясында.**<br><br>Татар әдипләре, җырчылары, композиторлары, рәссамнары, сәнгать тарихына кергән һәм бүгенге көндә иҗат итүче сәнгать эшлеклеләре турында кыскача белешмә: К.Насыйри, Г. Тукай, Г. Камал, М. Җәлил, Ш.Галиев, Ф.Яруллин, Т.Миңнуллин, Р.Миңнуллин, Р.Вәлиева.<br><br>Композиторлар: С. Сәйдәшев, З.Яруллин, С. Садыйкова, Р. Яхин, Н.Җиһанов.<br><br>Рәссамнар: Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Б. Урманче. | |

| Сөйләм эшчәнлеге төрләре | Укучыларның төп эшчәнлек төрләренә характеристика |
|---|---|

| Коммуникатив күнекмәләр | |
|---|---|
| **Диалогиксөйләм**<br><br>Тормыш-көнкүреш, уку, хезмәт, ял итү сфераларында этикет нормалары нигезендә төзелгән диалог формалары: хәбәр итү, тәкъдим итү, сорау, сораштыру, инкарь итү, теләк белдерү, үтенү, риза булу (булмау).<br><br><br><br><br><br><br><br>**Монологиксөйләм**<br><br>Сөйләмнең коммуникатив типларын кулланып (хәбәр итү, сурәтләп сөйләү), терәк сүзләр, сюжетлы рәсемнәр, план нигезендә сөйләү. | Сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү.<br><br>Вакыйганы ачыклау максатыннан сораштыру.<br><br>Нәрсә дә булса эшләүне, үзеңә ярдәм итүне үтенү.<br><br>Риза булмау, үтенечне кире кагу.<br><br>Бергә эшләргә тәкъдим итү.<br><br>Котлау, теләк белдерү.<br><br>Татарсөйләмэтикетыүрнәкләреннәнурынлыфайдаланып, әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү.<br><br>Парлап яки күмәк сөйләшүбарышында,үзфикереңнеаңлата, раслый, дәлиллибелү, ситуацияаңлашылмаганда, сораубирепачыклау.<br><br>Терәксхемаларкулланып, ситуациябуенчаәңгәмәкорабелү.<br><br>Монологиксөйләмдәкереш, эндәшсүзләрнекулланып, орфоэпикһәмграмматикнормаларнысаклап, үзфикереңнетөгәлҗиткерү.<br><br>Сораулар ярдәмендә, план буенча яисә мөстәкыйль рәвештә өйрәнгәнтекстныүзсүзләреңбелән сөйләү.<br><br>Текстныдәвам итеп сөйләү.<br><br>Тектны үзгәртеп сөйләү.<br><br>Программадатәкъдимителгәнтемаларбуенчатиешлеэзлеклелектәтексттөзеп сөйләү.<br><br>Өйрәнгән шигырьләрнеяттан |

| | |
|---|---|
| **Тыңлапаңлау**<br><br>Аралашу барышындачит сөйләмне ишетеп аңлау.<br><br>Зур булмаган текстларны аудиоязмада тыңлап аңлау.<br><br>**Уку**<br><br>Программадатәкъдимителгән әдәби әсәрләрне, әсәрләрдән өзекләрне, автор текстларын, орфоэпик нормаларны саклап, сәнгатьле уку.<br><br>Зур булмаган текстларны үзлектән аңлап уку.<br><br>Тәкъдим ителгән әдәби әсәрләрне сүзлек кулланып уку. | сәнгатьлесөйләү.<br><br>Төрлевакыйгалар, яңалыклартурындахәбәритү.<br><br>Персонажларны тасвирлау.<br><br>Төрлетөрдәгетыңлапаңлаукүнегүләренүтәү.<br><br>Сүзләрне, җөмләләрне тыңлапаңлаптәрҗемәитү.<br><br>Сыйныфташларыңның сөйләментыңлапаңлауһәмаларгаүзфикереңнеаңлату, аларбеләнәңгәмәкору, әңгәмәдәкатнашу.<br><br>Тәкъдимителгәнтекстнытыңлап, эчтәлегебуенчасорау җөмләләр төзү,сорауларгаҗавапбирү.<br><br>Зурбулмаганаутентивякиадаптацияләнгәнәдәбиәсәрләрдәнөзекләрне, мәгълүматихарактердагытекстларны, вакытлы матбугат язмаларын аңлап, эчтәлегебуенчафикереңнеәйтү.<br><br>Татартеленең әйтелешнормаларынсаклап, сәнгатьлеһәмаңлапуку.<br><br>Текстның эчтәлегенәнигезләнеп, контекстбуенчаяңасүзләрнең мәгънәсенаңлау.<br><br>Танышбулмагантекстныэчтәнукып, аның төпфикеренбилгеләү.<br><br>Текстны микротекстларга бүлеп уку, исем кую.<br><br>Текстның исеменнән чыгып яисә таныш лексикага таянып, текстның эчтәлеген фаразлау.<br><br>Танышбулмагансүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсенсүзлектәнтабу. |

| | |
|---|---|
| **Язу**<br><br>Программага кертелгән сүзләрне дөрес язу.<br><br>Вакыйганы хикәяләп язу.<br><br>Картинаны сурәтләп язу.<br><br>Прагматиктекстлар (рецептлар, белдерүләр, афишаһ.б.), эпистоляржанртекстларын (шәхсиһәмрәсмихатлар, котлауларһ.б.) язу. | Укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау.<br><br>Өйрәнелгәнтемаларбуенчаактивкулланылыштабулган сүзләрнедөресязу.<br><br>Конкретбертемабуенчахикәятөзеп язу.<br><br>Прагматиктекстлар (рецептлар, белдерүләр, афишаһ.б.), эпистоляржанртекстларын (шәхсиһәмрәсмихатлар, котлауларһ.б.) төзеп язу.<br><br>Үзеңнеборчыганпроблемагакаратафикерләреңнеязмачаҗиткерү.<br><br>Тәкъдимителгәнтекстның эчтәлегенәнигезләнеп, аныүзгәртепякидәвамитепязу. |

| | |
|---|---|
| **Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре** | |
| **Графика, каллиграфия, орфография** | |
| Аваз-хәреф мөнәсәбәтләре. Транскрипция билгеләре. Уку һәм язу кагыйдәләре. Сүзне юлдан юлга күчерү. Җөмләне баш хәрефтән яза башлау. Ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән язу. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре (нокта, сорау һәм өндәү билгеләре). | Хәрефләр белдергән авазларны транскрипция билгеләре белән язу.<br><br>Җөмлә чикләрен таба алу, язуда күрсәтә белү.<br><br>Сүзләргә төшеп калган хәрефләрне куеп язу.<br><br>Сүзләрне юлдан юлга күчереп язу.<br><br>Язу һәм укуның төп кагыйдәләрен, программада бирелгән сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын белү. |
| **Сөйләмнең фонетик ягы** | |
| Татар теленең авазлар системасы: сузык һәм тартык авазлар составы. Тартык авазлар үзенчәлеге ([къ], [гъ], [w], [ж], [ң], [һ], [ч] [‘] (һәмзә), ике тартык янәшә килгән сүзләр (*аккош, китте)*. Ике авазга билге булып йөрүче *я, ю, е* хәрефләре.Дифтонглар. Сингармонизм законы. Сингармонизм законына буйсынмау очраклары. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр. Кыска һәм озын сузыклар. Яңгырау тартыкларның иҗек яки сүз ахырында саңгыраулануы. Сүз, фраза басымы һәм аның үзенчәлекләре. Басым астында әйтелмәгән сузыкларның кыскаруы (редукция). Җөмләнең мәгънәви төркемнәргә бүленеше. Хикәя, боеру, тойгылы җөмләләрнең ритмик-интонацион үзенчәлекләре. Санау интонациясе. Сөйләм этикеты үрнәкләренең интонациясе. | Татар теленең барлык авазларын дөрес әйтә белү.<br><br>Сүз, җөмлә, текст эчендә бирелгән авазларны күрсәтә белү.<br><br>Телдән сөйләм яисә кычкырып уку барышында, татар теленә хас авазларның әйтелеш нормаларын саклау.<br><br>Сүз, фраза басымын дөрес куеп уку.<br><br>Җөмләләрнең ритмик-интонацион үзенчәлекләренә карап, төрләрен (хикәя, боеру, тойгылы) аера белү.<br><br>Тиңдәш кисәкле җөмләләрне дөрес интонация белән укый белү. |

| Сөйләмнең лексик ягы | |
|---|---|
| Гомуми (урта)мәктәптә аралашу темаларына караган 1000 гә якын лексик берәмлекне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Гади тотрыклы гыйбарәләр, татар сөйләм этикеты берәмлекләре, клишелар. Татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләр. Алынма сүзләр. Сүз ясалышы: парлы, кушма һәм тезмә сүзләр. Күп мәгънәле сүзләр. | Телдән һәм язма сөйләмдә программага кертелгән лексик берәмлекләрне дөрес әйтү һәм куллану.<br><br>Сөйләмдә коммуникатив максатка туры килгән гади тотрыклы гыйбарәләр, клишелар куллану.<br><br>Сүзләрне тематикага карап берләштерү (аерып алу).<br><br>Сүзләргә ялганган аффиксларның төрләрен тану, аеру. |
| **Сөйләмнең грамматик ягы** | |
| **Исем.** Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрнең тартым, килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең ясалышы (тамыр, парлы, тезмә, кушма, кыкартылма). Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. | Исемнең сан, тартым, килеш кушымчаларын сөйләмдә урынлы куллану. |
| **Сыйфат.** Сыйфатның гади, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләре. Ясалма сыфатлар.<br><br>**Сан.** Микъдар саннары (1000 гә кадәр), тәртип саннары (100 гә кадәр). Микъдар саны белән исем рәттән торганда, исемнең берлек санда гына кулланылуы. | Сыйфат дәрәҗәләрен аера алу, чагыштыру, артыклык дәрәҗәләренә куя белү, сөйләмдә куллана белү.<br><br>Микъдар, тәртип, җыю, чама, бүлем саннарын аера белү; татар һәм рус телләрендә *микъдар саны + исем* төзелмәсе кулланышы аермасын белү. |

| | |
|---|---|
| **Рәвеш.** Рәвеш төркемчәләреннән саф (тиз, акрын, җәяү һ.б.), күләм-чама (күп, аз, бераз), охшату-чагыштыру (татарча, русча, зурларча һ.б.), вакыт (иртәгә, бүген, җәен, кичен һ.б.), урын (анда, монда, якында, еракта, уңга, сулга һ.б.). | Актив кулланылыштагы саф (тиз, акрын, җәяү һ.б.), күләм-чама (күп, аз, бераз), охшату-чагыштыру (татарча, русча, зурларча һ.б.), вакыт (иртәгә, бүген, җәен, кичен һ.б.), урын (анда, монда, якында, еракта, уңга, сулга һ.б.) рәвешләрен сөйләмдә дөрес куллану.<br><br>Зат, сорау, күрсәтү, билгеләү, билгесезлек, юклык алмашлыкларын сөйләмдә тану, дөрес куллану. |
| **Алмашлык.** Зат, сорау, күрсәтү (*бу, әнә, менә*), билгеләү *(барлык, бөтен, үз, һәр)*, билгесезлек *(әллә кем, әллә нинди, кайбер)*, юклык *(беркем дә, бернәрсә дә, һич)* алмашлыклары.<br><br>**Фигыль.** Фигыль төркемчәләре: 1)**Хикәя фигыль.** Хикәя фигыльнең хәзерге, билгеле һәм билгесез үткән заман,<br><br>билгеле һм билгесез киләчәк заман формалары. Барлыкта һәм юклыктазат-сан белән төрләнеше.<br><br>2)**Боерык фигыль**. Боерык фигыльнең 2, 3 зат берлек һәм күплек сан формалары Боерык фигыльләрдә басым үзенчәлеге.<br><br>3) **Теләк фигыль.** Теләк фигыльнең 1 нче зат берлек һәм күплек сан формалары. | Сөйләм барышында программага кертелгәнхикәя фигыль, боерык фигыль, шарт фигыль, инфинитив, сыйфат фигыль, хәл фигыль формаларын тану, аңлап куллану:<br><br>1) хикәя фигыльнең заман формаларын аеру; барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен белү;<br><br>2) боерык фигыльләрне дөрес басым белән әйтү; 2 нче зат боерык фигыльне барлыкта һәм юклыкта куллана белү; 3 нче зат боерык фигыльне сөйләмдә аера белү;<br><br>3) сөйләмдә теләк фигыль формасын урынлы куллану;<br><br>4) инфинитив формасын модаль сүзләр белән актив сөйләмдә куллану;<br><br>5) сыйфат фигыльнең программада күрсәтелгән формаларын сөйләмдә тану;<br><br>6) хәл фигыльнең программада күрсәтелгән формаларын сөйләмдә тану, аңлап куллану.<br><br>Процессның башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын белдерә торган аналитик фигыльләрне; теләк, мөмкинлек/мөмкин түгеллек, кирәклек/кирәк түгеллекне белдерә торганмодаль мәгънәлеаналитик фигыльләрне тану һәм гамәли куллану. |

| | |
|---|---|
| 4)**Шарт фигыль**. Шарт фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. Кире шарт фигыль.<br><br>5)**Инфинитив.**Инфинитив формасының модаль сүзләр белән *(кирәк (түгел), тиеш (түгел), ярый (ярамый)* сөйләмдә кулланылышы.<br><br>6) **Сыйфат фигыль.** Хәзерге һәм үткән заман сыйфат фигыльнең *-учы/-үче; -а/-ә,-ый/-и торган; -ган/-гән,-кан/-кән* формалары.<br><br>7)**Хәл фигыль.** Хәл фигыльнең *-ып/-еп/-п; -гач/-гәч, -кач/-кәч; -ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче* формалары.<br><br>**Аналитик фигыльләр.** Процессның башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын *(укый башлады, укып тора, укып бетерде),* теләкне *(барасым килә)*, мөмкинлек/мөмкин түгеллекне *(бара алам, бара алмыйм)* белдерә торганмодаль мәгънәлеаналитик формалы фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы.<br><br>**Бәйлекләр**: *белән, турында, өчен, кебек кадәр, соң, аша.* Бәйлекләрнең исемнәр һәм алмашлыклар белән кулланылышы.<br><br>**Бәйлек сүзләр**: *алдында, артында, астында, өстендә, эчендә, янында*. Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең җөмләдә кулланылышы.<br><br>**Кереш сүзләр.***Бәлки, билгеле, беренчедән, икенчедән, минемчә, синеңчә, кызганычка каршы,* | Бәйлекләрне, бәйлек сүзләрне, кереш сүзләрне, теркәгечләрне, кисәкчәләрне сөйләмдә урынлы куллану. |

| | |
|---|---|
| *бәхеткә каршы* кереш сүзләренең сөйләмдә кулланылышы.<br><br>**Теркәгечләр.** Җыючы теркәгечләр: *һәм, да – дә, та – тә,*; каршы куючы теркәгечләр: *ләкин, тик, әмма, ә*; ияртүче теркәгечләр: *чөнки, әгәр.*<br><br>**Кисәкчәләр:** *-мы/-ме, бик, түгел, тагын, әле.* Кисәкчәләрнең дөрес язылышы, сөйләмдә кулланылышы.<br><br>**Җөмләнең төп коммуникатив төрләре:** хикәя, сорау, боеру җөмләләр. Татар җөмләсендә сүз тәртибе. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Гади фигыль хәбәрле (*Мин татарча беләм),* исем хәбәрле (*Безнең гаиләбез тату)* һәм тезмә фигыль хәбәрле (*Мин укырга яратам)* гади җөмлә. Гади җәенке җөмләләр. Тиңдәш кисәкле җөмләләр. *Һәм, ә, ләкин, чөнки* теркәгечләренең җөмлә төзүдә кулланылышы.<br><br>**Кушма җөмлә.** Тезмә кушма җөмләләр: теркәгечле, теркәгечсез төрләре. Иярчен кушма җөмләләрнең киң кулланылышта йөргән аналитик һәм синтетик төрләре: вакыт, урын, максат, сәбәп, шарт, кире җөмләләр. | Сөйләм нормаларын саклап, хикәя, сорау, боеру җөмләләр, раслау һәм инкарь җөмләләр төзү.<br><br>Тиңдәш кисәкле гади җөмләләр.<br><br>Теркәгечле, теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр.<br><br>Иярченле кушма җөмләләрнең түбәндәге аналитик һәм синтетик төрләрен сөйләмдә куллану:<br>– иярчен вакыт җөмләнең *кайчан-шунда (шул вакытта, шул чагында)* парлы мөнәсәбәтле сүзләре ярдәмендә ясалган аналитик төре;<br>– иярчен вакыт җөмләнең хәл фигыльнең *-гач/-гәч, -ганчы/-гәнче* формалары ярдәмендә ясалган синтетик төре;<br>– иярчен урын җөмләнең *кайда-шунда, кая-шунда, кайдан-шуннан* парлы мөнәсәбәтле |

| | |
|---|---|
| | сүзләре ярдәмендә ясалган аналитик төре;<br>– иярчен максат җөмләнең *шуның өчен* ялгызакмөнәсәбәтле сүзе белән бәйләнгән аналитик төре;<br>– иярчен максат җөмләнең *өчен* бәйлеге белән ясалган синтетик формасы;<br>– иярчен сәбәп җөмләнең *шуңа күрә, шул сәбәпле* ялгызак мөнәсәбәтле сүзләре белән ясалган аналитик төре;<br>– иярчен шарт җөмләнең шарт фигыль кушымчасы ярдәмендә ясалган синтетик төре*;*<br>– иярчен кире җөмләнең кире шарт фигыль формасы ярдәмендә ясалган синтетик төре. |

## 5 нче сыйныфлар өчен программа эчтәлеге

| № | Бүлекләр, темалар | Сәг. саны | Темага караган төп төшенчәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | **Без мәктәптә.** | 20 | Кем? Кемне? Кемгә сораулары; Кая? Кайда? Кайдан? Сораулары, Кайдан?соравы. Уку – язу әсбаплары. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе. Тартым белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре. Боерык фигыль. Боерык ф-нең барлыкта һәм юклыкта төрләнеше. Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта 2 нче затта төрләнешен сөйләмдә куллану. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. Исемнәрнең ясалышы. Тамыр, кушма парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә куллануын кабатлау. - *лык\-лек,* -*даш\-дәш,-таш\-тәш* исем ясагыч кушымчалар белән танышу. Хәзерге заман хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат –сан белән төрләнеше. Хәзерге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | заман хикәя фигыльнең барлык формасының зат -сан белән төрләнеше. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасының зат-сан белән төрләнеше. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык-юклык формасы Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат- сан белән төрләнеше. Чөнки, ләкин теркәгечләре.<br>Сан төркемчәләре. Микъдар, тәртип, җыю саннарын аера белү. |
| 2. | **Мин-өйдә булышчы.** | 16 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. Чөнки, ләкин теркәгечләре.<br>Өчен, шикелле бәйлекләрен сөйләмдә куллану.<br>Кереш сүзләр. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу. Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану. Фигыльнең инфинитив формасы. (сузыкка беткән фигыльләр) .Фигыльнең инфинитив формасы. (тартыкка беткән фигыльләр);<br>Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | куллану. Теләк фигыльнең барлык, юклык формасы. Минем өчен төзелмәсе. Үзем алмашлыгы; Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы; Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең берлектә һәм юклыкта зат – сан белән төрләнеше; |
| 3. | **Дуслар белән күңелле.** | 16 | Эшләргә телим конструкциясе. Сыйфат сүз төркеме; Сыйфат дәрәҗәләре; Гади һәм тезмә фигыл.***;*** Үтенүне белдерүче фигыльләр.Чөнки теркәгече; Исемнең килеш белән төрләнеше.Үткән заман хикәя фигыль; Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта, зат-сан белән төрләнеше. Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең күплектә зат – сан белән төрләнеше.Бәйлек сүзләр. Эшләргә телим конструкциясе. |
| 4. | **Дүрт аяклы дусларыбыз.** | 10 | Тартым (-ныкы,-неке) кушымчалары. Исемнең килеш белән төрләнеше. Килеш белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү. Зат алмашлыкларның килешләр белән төрләнеше. Мин, син, ул зат алмашлыкларының, төшем |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | килешләрендә сөйләмдә куллана белү. Зат алмашлыклары. Зат алмашлыкларының төшем ,урын-вакыт, юнәлеш килешендә төрләнеше. Зат талмашлыкларының төшем килешендә төрләнеше. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. |
| 5. | **Без спорт яратабыз.** | 9 | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнешен ныгыту; ***лык\-лек***-исем ясагыч кушымчалары.Җөмләдә ия белән хәбәрнең зат-санда ярашуы. Җөмләнең баш кисәкләре. |
| **Барлыгы** | | 70 | |

**5нче сыйныф өчен уку елы дәвамында формалаштырырга тиешле белем һәм күнекмәләр**

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре.

2. Тартым һәм килеш белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү.
3. Тамыр, кушма парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә кулллануын кабатлау.
4. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.
5. Сыйфат дәрәҗәләре белән таныштыру, аларны сөйләмдә куллану.
6. Микъдар, тәртип, җыю саннарын аера белү.
7. Мин, син, ул зат алмашлыкларының, төшем килешләрендә сөйләмдә куллана белү.
8. Зат алмашлыкларының урын-вакыт килешендә сөйләмдә куллану.
9. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
10.Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.

11.Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.

12.Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта 2нче затта төрләнешен сөйләмдә куллану.

13.Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану.

14.Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә куллану

15.. Эшләргә телим – төзелмәсен сөйләмдә куллану.

16.Өчен, шикелле бәйлекләрен сөйләмдә куллану.

17.Кереш сүзләрне (минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә) сөйләмдә куллану.

**6нчы сыйныф өчен программа эчтәлеге.**

| № | Бүлекләр,<br><br>темалар | Сәг.<br><br>саны | Темага караган төп төшенчәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | **Яңа уку елы башлана** | 19 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Исем ясагыч кушымчалар һәм аларның кулланылышы. Туры сөйләм.Боерык фигыльне барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндерү. Белән, кебек, өчен, соң, аша бәйлекләрен исемнәр һәм алмашлыклар белән сөйләмдә кулланышы. |
